# Кышка кергәч, керәшендә Нардуганнар башлана



Елның иң гүзәл чоры кайчан, дип сораганда, һич шикләнмичә, кыш көне дип җавап бирәм. Яңа ел чыршы бәйрәмнәре өчен генә түгел. Качману вакытындагы чатнама суыклары, адаштыра торган ак бураннары өчен яратам мин кышны. Балачак хатирәләре булып күңелгә кереп калган ямьле Нардуган бәйрәме дә бары кыш көне була.

(Дәвамы 8 нче биттә).



# Кышка кергәч, керәшендә Нардуганнар башлана



Без кечкенә чакларда Нардуган көннәрендә бик суык була торган иде. Өйләр дә утын белән генә җылытыла. Шундый төннәрдә Нардуган бабайлар йөри, ачылган ишектән алар белән бергә ыжгырып салкын керә. Ләкин берәү дә зарланмый, берәү дә ишеген бикләп куймый. Өйгә кергән һәр Нардуган һөнәрен күрсәтә: кайсы җырлый, кайсы бии, кайсы күрәзә карый. Һәркемгә күңелле, рәхәт. Без, балалар, чаршау артына посып кына аларга такмак әйтәбез:

Нардуган, Нардуган,
Безгә дигән бүләкләрен
"Капыйлар"да калдырган...

Ә Нардуган бабайлар:

— Менә сезгә күчтәнәч, — дип, кесәләреннән конфет-прәннек чыгарып бирәләр. Шул вакытта шатлыкларыбызга чик-чама булмый...

Бу хатирәләрне искә төшерсәм, күңелне сагыш биләп ала. "Их, шул чакларны кире кайтарып булсын иде", — дип куясың.

Бик теләсәң, кайтарып була икән ул онытылган бәйрәмнәрне. Соңгы ун-унбиш елда никадәр йолаларыбыз, бәйрәмнәребез халыкка кире кайтарылды. Шуларның иң күркәмнәреннән берсе — Нардуган бәйрәме.

Бу бәйрәм Чаллы шәһәрендә быел ундүртенче тапкыр үткәрелде. С.Садыйкова исемендәге концертлар залы халык белән шыгрым тулган иде. Залга үтәргә теләп тә, урын булмау сәбәпле керә алмаучылар тагын күпме калды. Сагынган, бик сагынган халык үзенең яраткан бәйрәмен. Әлеге чараны үткәрүгә шәһәр мэры И.Халиков зур матди һәм материаль ярдәм күрсәткән. Шулай ук керәшеннең асыл егетләре А.Аппаков, А.Высоцкий, Г.Стрелков, В.Агапов җитәкчелегендәге "Моңлы Чаллы" театры коллективы "Нардуган"ның тиешле югарылыкта үтүе өчен шактый күләмдә спонсор көче керткәннәр. Бәйрәмне оештыручы һәм үткәрүче — Н.П.Ипеев җитәкчелегендәге керәшен җәмгыяте, алып баручы — хакимиятнең физкультура һәм спорт идарәсе башлыгы урынбасары Р.Д.Ипеева. Шәһәр хакиме урынбасары Х.Ф.Галәветдинов бәйрәмгә җыелган халыкка котлау чыгышында бу бәйрәмне үткәрүнең матур традициягә әйләнүен әйтте, "әгәр дә Нардуган үткәрелмичә калса, шәһәр тормышында ниндидер китеклек булыр төсле" дип билгеләп үтте.

Чаллы шәһәренең "Карендәшләр" керәшен фольклор ансамбле артистлары бәйрәмнең чын хуҗалары булдылар. Атнакөн мәктәбе укучылары да зур әзерлек белән килгәннәр иде. Нардуганга күчтәнәчсез йөрмиләр. Чаллы техник колледж директоры П.Кудряшов үзләрендә эшләп килүче "Чулпан" бию ансамблен китергән. Мондагы егетләр гади агач кашыклар белән төрле көйләр чыгарып, бер үк вакытта җитез бию хәрәкәтләре ясап, тамаша залына яшьлек рухын тараттылар. Егетләр һәм кызлар башкаруындагы керәшен биюе дә тамашачы күңеленә хуш килде.

Быелгы Нардуганга күп яңалык кертелгән. Шәмнәр белән күрәзә карау күренеше залдагы халыкны бер мәлгә өнсез калдырды. Нардуган чорында яше-карты язмыш сыный торган булган. Бу көнне дә күпләр үз язмышларын сынап карарга булдылар. Күрәзәче Мортазина Римма ил күләмендә танылган Лилианалардан бер дә ким түгел иде: аның киемнәре, үз-үзен тотышы, әйткән сүзләре һәркемне ышандырырлык булды. Быелгы Эт елында Түбән Мәләкәс егете Василий машиналы, Минзәлә районы Иркәнәш авылыннан Зөһрә — киленле булачак, ә Мәләкәстән Света яңа дуслар табачак, Роза иренә карата мәхәббәтен яңартачак һ.б.лар. Күрәзәче Римма юрау күренеше азагында:

— Безгә ышаныгыз, ләкин йөрәгегез кушканча эшләгез, — диде.

Бу сүзләрне һәркем исеннән чыгармасын иде. Юрау ул — күңелең бик нык теләгән әйберне күрү, булдыру. Язмышны үзгәртү кешенең үз кулында.

Нардуган бәйрәменә кунакка Алабуга районыннан "Ак каз" (җитәкчесе В.Мироваев), Сарман районы Ләке авылыннан "Игәнәй" (җитәкчесе Р.Анисимова), Тукай районы Мәләкәс авылыннан "Питрау" (җитәкчесе Р.Семенова) фольклор ансамбльләре дә килгән иде. Репертуарда борынгы җырлар да, заманча җырлар да күп булды, искиткеч осталык белән башкарылган җырларны тамашачы тын да алмый тыңлады, җыр тәмамлангач, зур алкышларга күмде.

Тамашачы турында да җылы сүз әйтәсе килә. Һәр чыгышны шулкадәр яратып, үз итеп кабул иттеләр, дүрт сәгатькә сузылган тамашадан берәү дә чыгып китмәде. Яшь бала белән килүчеләр дә азакка кадәр утырдылар.

Нардуган башланганчы да, тәнәфес вакытында да "Туганайлар" газетасына язылу оештырылды. Тамашачыга дини, энциклопедик китаплар, календарьлар сатып алырга мөмкин иде. Бу көнне 50 газета укучыбыз артты.





Бәйрәм башыннан алып ахырына кадәр сәхнәләштерелгән күренешләр белән үрелеп барды. Марина Майорова тудырган "Марҗук" образы тамашачыны рәхәтләнеп көлдерде, "Карендәшләр" күрсәткән "Туй күренеше" күзләрне яшьләндерде.

Авыл эте Акбай, Шәһәр эте Чарли һ.б. бик күп кунаклар 2006 кызыл Эт елында илгә тынычлык, халыкка муллык, җитәкчеләр күңеленә игелек теләделәр. "Моңлы Чаллы" ансамбленең яшь артистлары Л.Сафина, И.Гомәров, "Карендәшләр"дән Л.Мортазина, техник колледждан И.Хәлимов, 54 нче гимназиядән Д.Хуҗина башкарган җырларны, кечкенәләрдән А.Әхмәтшина, София һәм Валерия Храмовалар уйнаган көйләрне тыңлап, халкыбызның җыр дөньясы нинди тирән булуына тагын бер тапкыр сокландык.

Нардуган бәйрәменең ахырында ТР атказанган артисты В.Агапов үзе иҗат иткән дәртле җырларны башкарды, тамашачы аңа кушылып җырлады, биеде, бергәләп сызгырды. Яраткан җырчысын сәхнәдән җибәрергә теләмәде...

15 январь көнне шәһәргә Качману салкыннары килеп җитте. Ләкин тамашага килгән халык бу суыкны тоймагандыр, дип уйлыйм, чөнки бәйрәмнән алган тәэсир, күңел күтәренкелеге әллә нинди суыкларга да бирешерлек түгел иде.

**М.МАРТЫНОВА.**